Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ерсубайкино авыл Советы
КАРАРЫ

19 ноябрь 2020 ел №8

Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл Советының 2018 елның 24 августындагы «Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы 66 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүне камилләштерү, муниципаль хезмәткәрләрне кызыксындыру, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, "Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2007 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы ТР Кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге 940 нчы карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актлар белән расланган карары нигезендә

Ерсубайкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 66 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә

ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары 4 пунктында «4,65» санын «6,72» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Ерсубайкино авылы, Совет урамы, 11 йорт, Яңа Елань авылы, Үзәк урам, 35 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ерсубайкино авылы
җирлеге Башлыгы

Е.Г. Николаева